**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ МОРДОВСКО-АФОНКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**МОРДОВСКОЕ АФОНЬКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423103, Мордва Афонькэсе авылы, Цаплин урамы, 19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru

16.06.2021 № 29

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2013 елның 2 апрелендәге 309 номерлы һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2013 елның 2 апрелендәге 310 номерлы, «Санлы финанс активлары турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-328 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында» Указы, «Санлы финанс активлары,

цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» һәм коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 3 июнендәге ПУ-427 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2013 елның 12 февралендәге 56 номерлы «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Мордва Афонькәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Чирмешән муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны рәсми хокукый порталда (pravo.tatarstan.ru) дәүләт теркәвенә алынганнан соң бастырып чыгарырга һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Мордва Афонькәсе авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **А.И.Митяев**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
Советының 2021 елның 16 июнендәге
29 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең (алга таба - муниципаль хезмәткәр), аларның ирләренең (яки хатыннарының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны (алга таба-мәгълүматлар) Чирмешән муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) урнаштыру процедурасын, шулай ук әгәр федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән әлеге мәгълүматларны урнаштыру һәм (яисә) аларны массакүләм мәгълүмат чараларына бирүнең башка тәртибе билгеләнмәгән булса, соратулары буенча әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен гомумроссия, республика һәм муниципаль массакүләм мәгълүмат чараларына (алга таба - массакүләм мәгълүмат чаралары) бирүне регламентлый.

2. Рәсми сайтта урнаштырыла һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен түбәндәге мәгълүматлар бирелә:

а) муниципаль хезмәткәргә, аның хатынына (иренә) һәм балигъ булмаган балаларга милек хокукында яки аларның файдалануында булган күчемсез милек объектлары исемлеге, аларның һәркайсының төрен, мәйданын һәм урнашу илен күрсәтеп;

б) муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукында булган, төре һәм маркасы күрсәтелгән транспорт чаралары исемлеге;

в) муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме;

г) җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешен), санлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләр кылган акчалар алу чыганаклары турында

белешмәләр, әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы затның, муниципаль хезмәткәрнең һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешкә кадәрге соңгы өч елда гомуми кереметннән артып киткән очракта, һәм алыш-биреш кылган акчалар алу чыганаклары турында белешмәләр.

3. Рәсми сайтта урнаштырыла торган һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирелә торган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларда күрсәтү тыела:

а) муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, атап үтелгән затларга милек хокукында булган мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында башка белешмәләр (әлеге Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгәннәрдән тыш);

б) муниципаль хезмәткәр хатынының (иренең), балаларының һәм башка гаилә әгъзаларының шәхси мәгълүматлары;

в) муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең), балаларының һәм гаиләнең башка әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка индивидуаль коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар;

г) муниципаль хезмәткәр, аның хатыны (ире), балалары, гаиләнең башка әгъзалары карамагындагы милек хокукында яки аларның файдалануында булган күчемсез милек объектларының булу урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар;

д) дәүләт серенә кертелгән яки конфиденциаль булып торучы мәгълүмат.

5. Әлеге Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән срок чыкканнан соң 14 көн эчендә рәсми сайтта урнаштырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны рәсми сайтта урнаштыру кадрлар хезмәте (кадрлар хезмәте бүлекчәсе, җирле үзидарә органының кадрлар эше һәм муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча белгеч (алга таба-кадрлар хезмәте) белән тәэмин ителә.

7. Җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләре:

а) запрос кергән көннән 3 көн эчендә аның турында запрос кергән муниципаль хезмәткәркә хәбәр итәләр;

б) массакүләм мәгълүмат чараларыннан запрос кергән көннән 7 көн эчендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны, соратып алына торган мәгълүматлар рәсми сайтта булмаса, бирүне тәэмин итәләр.

8. Рәсми сайтта урнаштырылган мәгълүматлар, шул исәптән алдагы еллар өчен дә:

- бетерелергә тиеш түгел;

- муниципаль хезмәтнең бөтен чоры дәвамында ачык керү мөмкинлегендә урнашкан (рәсми сайтларда урнаштырылган).

9. Муниципаль хезмәткәрләргә төгәлләштерелгән белешмәләр биргәндә, тиешле үзгәрешләр рәсми сайтта урнаштырылган белешмәләргә төгәл мәгълүматлар бирү өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 14 эш көненнән дә соңга калмыйча кертелә.

10. Кадрлар хезмәтенең муниципаль хезмәткәрләре Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге Тәртипне үтәмәгән өчен, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яки конфиденциаль булып торган белешмәләрне игълан иткән өчен җаваплы.